ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

### 1 статья

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш); 2009, № 1; 2012, № 6 (I өлеш); 2014, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 17 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкалары Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.».

### 2 статья

«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2016 елның 13 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 1 – 2; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш), «тарафыннан» сүзеннән соң «, Россия Федерациясе Салым кодексының

284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш), «тарафыннан» сүзеннән соң «, Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**4 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 2022 елның 21 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 24 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Региональ инвестиция проектларында» сүзләрен «1. Региональ инвестиция проектларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкасы Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.».

**5 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 91-ТРЗ